**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.08.2020 № 782

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында МФЦ ДБУнең Кама Тамагы филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 969 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2019 елның 02 октябрендәге 795 номерлы карар редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында МФЦ ДБУнең Кама Тамагы филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 969 номерлы карарына (2019 елның 02 октябрендәге 795 номерлы карар редакциясендә) кушымта нигезендә яңа редакциядә Татарстан Республикасында МФЦ ДБУнең Кама Тамагы филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 11 августындагы 782 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасында МФЦ ДБУнең Кама Тамагы филиалында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге**

| | |
|---|---|
| 1 | Күпфатирлы йортта бинаны яңадан үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү |
| 2 | Бинаны торак бина, торак урынны авария хәлендәге һәм реконструкцияләнергә яисә реконструкцияләнергә тиешле авария хәлендәге күпфатирлы йорт өчен яраксыз , торак йортны бакча йорты һәм бакча йортын торак йорт дип тану |
| 3 | Торак (торак булмаган) бинаны , торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү |
| 4 | Төзелешкә рөхсәт бирү |
| 5 | Индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве (туры килмәве) турында хәбәрнамәне җибәрү |
| 6 | Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү |
| 7 | Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзелгән яисә реконструкцияләнгән объектның шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамәне җибәрү |
| 8 | Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган җимерү турында хәбәрнамә һәм документлар җибәрү |
| 9 | Капиталь төзелеш объектын сүтеп бетерү турында хәбәрнамә җибәрү |
| 10 | Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү |

| | |
|---|---|
| 11 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү |
| 12 | Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү |
| 13 | Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп башкарыла торган шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү |
| 14 | Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар кабул итү |
| 15 | Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү |
| 16 | Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне бирү |
| 17 | Җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү |
| 18 | Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару |
| 19 | Белешмә (өземтә) бирү |
| 20 | Агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү |
| 21 | Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү |
| 22 | Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау |
| 23 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү |
| 24 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү |
| 25 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү |
| 26 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату |
| 27 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү |
| 28 | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү |
| 29 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион рәвешендә үткәрелә |

| | |
|---|---|
| | торган сатуларда арендага бирү |
| 30 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда сату юлы белән хосусый милек итеп бирү |
| 31 | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү |
| 32 | Муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү |
| 33 | Аерым максатларда гавами сервитут билгеләү |
| 34 | Крестьян (фермер) хуҗалыгы белән аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына муниципаль милектәге җир кишәрлеген милек буларак (арендага) бирү |
| 35 | Торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү |
| 36 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү |
| 37 | дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү |
| 38 | Хосусый яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка җиргә күчерү турында карар кабул итү |
| 39 | Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү |
| 40 | Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү |
| 41 | Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү |
| 42 | Милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак затларны исәпкә кую |
| 43 | Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут билгеләү турында килешү төзү |

| | |
|---|---|
| 44 | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга индивидуаль торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү |
| 45 | Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү |
| 46 | Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү |
| 47 | Муниципаль мөлкәт реестрыннан өземтә бирү |
| 48 | Муниципаль милектәге һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүмат бирү |
| 49 | Муниципаль казнаны тәшкил итүче мөлкәтне арендага бирү |
| 50 | Муниципаль мөлкәт реестрына керүче муниципаль мөлкәтне арендага бирү |
| 51 | торглар үткәрмичә муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыру |
| 52 | Мондый шартнамәне төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү |
| 53 | Муниципаль милекне арендалауның гамәлдәге килешүен өзү |
| 54 | Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү |
| 55 | Муниципаль милектәге өске су объектын яисә аның өлешен файдалануга бирү турында карар бирү |
| 56 | Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү |
| 57 | Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү |
| 58 | Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуларга рөхсәт бирү |
| 59 | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү |

| | |
|---|---|
| 60 | Муниципаль преференцияләр бирү |
| 61 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне биләүгә һәм (яисә) аннан файдалануга тапшыру |
| 62 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 63 | Хезмәт урыныннан наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү |
| 64 | Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү |
| 65 | Гражданга муниципаль торак фондының  социаль наем шартнамәсе буенча торак урынын бирү |
| 66 | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую |
| 67 | Авыл җирендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләүләр бирү |
| 68 | «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү һәм исәпкә кую |
| 69 | Торак урыннарга мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую |
| 70 | Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм аларга тиңләштерелгән затларга радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга дәүләт торак сертификатын исәпкә алу һәм бирү |
| 71 | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күченеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидияләр бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү |
| 72 | Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү |
| 73 | Дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклanучы архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү |

| | |
|---|---|
| 74 | Гражданнардан законсыз сакланган яки табылган корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр өчен түләүне башкару өчен документлар кабул итү |